Бүгенге көндә һәрбер телне мәдәниятара һәм шәхесара аралашу-аңлашу чарасы буларак укыту иң әһәмиятле мәсьәләләрдән санала, чөнки халыклар тыгыз рухи-мәдәни бәйләнештә яши, үзара якыная, дөнья зур бер фәнни-икътисади комплексны хәтерләтә. Ел саен дистәләгән халыкара форум һәм симпозиумнар, фәнни-гамәли конференция һәм дәүләтара очрашулар үткәрелә, һәм аларда глобальләштерү һәм мәдәниятара багланышлар чорында күптеллелек мәсьәләләрен хәл итү проблемалары карала. Социологлар билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта күптеллелек социаль-мәдәни күренешкә әйләнеп бара, чөнки дөнья халыкларының 75% ы ике яки күбрәк телдә сөйләшә. Гомумән, берничә тел белүченең һөнәри мөмкинлекләре арта, ул рухи яктан байый һәм мәдәниятләрне үзара бәйләүче шәхес буларак кабул ителә. Шунлыктан белем бирү сыйфаты ягыннан алга киткән илләрдә телләргә өйрәтүнең нәтиҗәлелеген яхшырту, информацион-коммуникатив технологияләрне гамәлгә кую мөһим эшләрдән санала. Аларны уңышлы хәл итү өчен, белем бирү программаларының эчтәлегенә, укыту һәм тикшерү методикаларына үзгәрешләр кертү сорала. Традицион укыту методларын камилләштерү белән бергә, инновацион формаларны – дистанцион укыту чараларын куллануга да игътибар көннән-көн арта бара. Бүгенге шартларда Интернет-технологияләр – телләргә өйрәтүдә иң үтемле чараларның берсе, чөнки алар белем алу процессын интенсивлаштыруга, аның сыйфатын яхшыртуга этәргеч булып тора. Шундыйларның берсен *дистанцион укыту системасы, укыту платформасы, электрон укыту платформасы* дип атыйлар. Укыту платформалары – онлайн-курсларны урнаштыру, алар белән идарә итү урыны. Алар аша тел өйрәнүче теләсә кайсы вакытта, интернет булган теләсә кайсы урында онлайн-мәктәпкә кереп шөгыльләнә ала [1: 10]. Телләргә өйрәтү тәҗрибәсе күрсәткәнчә, дистанцион курслар эчтәлеге, максат-бурычлары, күләме ягыннан төрле булырга мөмкин. Әмма аларның барысы да телне өйрәнүгә сарыф ителгән вакыт ягыннан күпкә отышлы, материалның бирелеше ягыннан уңайлы һәм матур бизәлешле. Моның белән берргәттән, алар тел өйрәнүченең индивидуаль үсешен, кызыксынуын үстерү өчен дә шартлар тудыра, аларның танып белү активлыгын, мөстәкыйль фикер йөртә алуын даими үстерә.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 нче маддәсе һәм «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы» Закон (1992) нигезендә татар һәм рус телләре – тигез хокуклы дәүләт телләре. Күпмилләтле Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәэмин итә. Республикада телләр сәясәтенең киләчәктә үсеш алуы, татар теленең гамәли һәм интеллектуаль тормышта урын алу-алмавы аны укыту дәрәҗәсенә дә бәйле. Мондый шартларда татар телен аралашу чарасы буларак укыту өчен, иң нәтиҗәле методик алымнарны куллану, информацион-коммуникатив технологияләрдән киң файдалану аеруча зур әһәмияткә ия. Соңгы елларда Татарстан Республикасы, Россиянең иң алдынгы төбәкләреннән берсе буларак, төрле инновацион проектларны гамәлгә ашыру, зур халыкара чаралар үткәрү урынына әверелде. Төрле юнәлешләрдә республика күпләргә үрнәк булып тора. Инновацияләр тормышның күп кенә өлкәләренә карый, шул исәптән мәгариф системасы да алардан читтә калмый. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую юнәлешендә республикада шактый зур эшләр башкарылып килә: федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә, татар теленнән үрнәк укыту программалары төзелде, урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре яңартылды; укучыларның татар теленнән белемнәрен тикшерү системасы халыкара стандартларга нигезләнеп үзгәртелде; электрон дәреслекләр булдырылды; югары уку йортлары өчен аерым фәннәрдән татар телендә дәреслекләр һәм сүзлекләр нәшер ителде; ел саен республика һәм халыкара олимпиадалар үткәрелә; укучылар өчен төрле иҗади бәйгеләр, фәнни-гамәли конференцияләр оештырыла һ.б.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы чит төбәкләрдәге мәктәпләрне дә татар теле һәм әдәбиятын өйрәнү өчен тиешле укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итә, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының һөнәри дәрәҗәсен күтәрүдә ярдәм күрсәтә, чит илләрдә яшәүче милләтәшләребезгә туган телдә аралашу күнекмәләре булдыру өчен, шартлар тудыра. Гомумән алганда, татар теле укытуның уңышлы һәм җитешсез яклары даими күзәтелеп бара, дәүләт органнары һәм җәмәгатьчелек оешмалары тарафыннан тикшерелә һәм бәяләнә дип әйтергә мөмкин. Мондый шартларда татар телен аралашу чарасы буларак укытуны тагын да камилләштерү, хәл ителәсе проблемалар турында ачыктан-ачык сөйләшүләр, фикер алышулар үткәрү, алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу, нәтиҗәле методик алымнарны тәкъдим итү һәм аларны гамәлдә куллануга ирешү зарур. Шулай эшләгәндә генә, бай тарихка ия булган татар лингвометодикасы заман таләпләреннән чыгып үсеш алыр һәм камилләшер дип күзаллана.

Бүгенге таләпләрнең иң мөһиме – белем бирү оешмаларында информацион-коммуникатив технологияләрне киң кулланылышка кертү эшенең актуальлеге шуның белән дәлилләнә. Әлеге тикшеренүнең максаты – татар теленә өйрәтүдә дистанцион технологияләрдән файдалану мәсьәләләрен яктырту, «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбенең төп эчтәлеген һәм мөмкинлекләрен ачып бирү [2]. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы EF компаниясе (инглиз теленә өйрәтүдә дөньякүләм танылган компанияләрнең берсе) белән берлектә гамәлгә ашырган әлеге проект татар теленә өйрәтүдә, һичшиксез, иң заманча укыту чарасы булып тора, чөнки аның ярдәмендә төрле илләрдә яшәүче төрле милләт вәкилләре дистанцион рәвештә татар телен гамәли үзләштерә ала. «АНА ТЕЛЕ» дистанцион мәктәбе – EF компаниясе платформасына урнаштырылган һәм дөньяда танылу алган алдынгы методик система нигезендә татар телен гамәли өйрәнүгә юнәлтелгән укыту чарасы ул. Курсның төп үзенчәлеге укыту алымнарының, эш төрләренең күплеге һәм аралашуның тыгызлыгы белән билгеләнә. Татар телен, аралашу чарасы буларак, интенсив үзләштерү, тел өйрәнүчеләрнең коммуникатив компетенцияләрен үстерү әлеге мәктәпнең төп максатлары булып тора. Аңа теркәлгән һәр кеше, татар телен гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия була ала. Дистанцион мәктәп тел өйрәнүчеләрнең аралашу осталыгын үстерүгә хезмәт итү белән бергә, аларны татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләре белән таныштыра, башка халыкларга карата хөрмәт хисе булдыруга этәргеч ясый. Шулай итеп, татар халкының мәдәнияте, рухи байлыгы һәр өйрәнүче тарафыннан дөнья мәдәниятенең бер өлеше буларак кабул ителә.

Татар теленә өйрәтүнең төп бурычлары түбәндәгечә билгеләнә: тел өйрәнүчеләрнең аралашу даирәсен, тормышчан ситуацияләрне исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләреннән (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) билгеле бер компетенцияләр формалаштыру; сөйләм культурасын үстерү; татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү; һәр катнашучыны мәдәниятара диалогка тарту.

Хәзерге вакытта белем бирү системасын, аеруча телләргә өйрәтүне мультимедиа технологияләреннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Алар тел өйрәнүчегә берьюлы графика, текст, видео, анимация, тавышлы эффектлардан файдаланырга мөмкинлек бирә [3: 315-316]. Шуңа күрә дә телләрне заманча өйрәтү өчен, күптөрле онлайн-курслар булдырылган. Методистлар фикеренчә, дистанцион курслар бары тик лексик-грамматик материалны мөстәкыйль рәвештә үзләштерү һәм уку-язу күнекмәләренә ия булуны гына максат итеп куймый, аларда телдән һәм язма сөйләмгә өйрәтү тулы бер методик системаны тәшкил итә. Онлайн-режимда тел өйрәнүчеләр, алган белемнәренә нигезләнеп, җанлы аралашу дәресләрендә катнаша, төрле җирләрдә яшәүче кешеләр белән таныша, көндәлек тормыштагыча бер-берсе белән әңгәмә кора һәм үзара аңлаша алалар. Билгеле булганча, дистанцион укыту системасы үзенчәлекле эш алымнарына мөрәҗәгать итә. Аның төп эчтәлеге һәр теркәлүчегә заманча һәм нәтиҗәле интерактив укыту методикасы ярдәмендә телне гамәли үзләштерү, телне белү дәрәҗәсен тикшереп карау, өстәмә ярдәмлекләрдән файдалану мөмкинлекләре булдырудан гыйбарәт.

Татар телен дистанцион нигездә укыту, беренчедән, тел өйрәнүчеләрдә *лингвистик компетенция* булдыруга китерә, чөнки алар, фонетик һәм лексик-грамматик материалны гамәли үзләштереп, сөйләмдә кулланырга

күнегәләр; икенчедән, аларның *сөйләм компетенциясе* үсеш ала, чөнки тел аралашу калыплары, диалогик һәм монологик сөйләм үрнәкләре аша актив өйрәнелә; өченчедән, тел һәм сөйләм берәмлекләре аша татар дөньясы турында мәгълүмат алып, алар *социаль-мәдәни компетенциягә* дә ия булалар [4: 9].

«АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе 2013 елның 1 гыйнварынннан эшли башлады. Анда берьюлы 10 000 кеше теркәлә ала, һәм аларга татар телен бер ел дәверендә өйрәнү хокукы бирелә. Теләге булган кеше тел өйрәнүне алга таба да дәвам итә ала. Онлайн-мәктәп барлыгы 9 дәрәҗәдән тора, һәм алар, халыкара тел компетенцияләре шкаласыннан чыгып караганда, A1, A2, B1 һәм B2 дәрәҗәләренә туры килә. Билгеле булганча, чит телләргә өйрәтү методикасында тел белүнең өч дәрәҗәсе күрсәтелә: телне элементар дәрәҗәдә белү (*A*); телне мөстәкыйль рәвештә куллана алу дәрәҗәсе (*B*); телне ирекле рәвештә куллана алу дәрәҗәсе (*C*). Аларның һәрберсе, үз чиратында, тагын икегә бүленеп, барлыгы алты дәрәҗә күрсәтелә (*A1, A2; B1, B2; C1, C2*). Бу бүленеш теге яки бу телне өйрәнүчеләрнең белем дәрәҗәләрен халыкара стандартлар нигезендә билгеләү һәм объектив бәя бирү өчен эшләнгән.

Онлайн-курсның һәр дәрәҗәсе, үз чиратында, 8 бүлектән (темадан) гыйбарәт. Димәк, татар телен башлап өйрәнүче барлыгы 72 бүлекне үтәргә тиеш була. Әлеге бүлекләр кешенең көндәлек тормышындагы аралашу ситуацияләрен исәпкә алып сайланган. *Гадидән катлаулыга* принцибыннан чыгып, беренче дәрәҗәләрдә «Танышу», «Төсләр һәм саннар», «Гаиләм», «Һава торышы», «Кибеттә» кебек темалар гамәли үзләштерелә. Алга таба тел өйрәнүчеләр тагын да киңрәк темалар кысаларында аралашырга-аңлашырга күнегәләр. Мәсәлән, «Сәламәтлек», «Эш эзләү», «Тормыш тәҗрибәсе», «Үзара мөнәсәбәтләр һәм хисләр», «Спорт белән шөгыльләнү», «Сәяхәт итү» һ.б. Соңгы дәрәҗәләрдә исә татар дөньясына караган темалар, Татарстан Республикасының төрле өлкәләрдәге казанышлары белән таныштыру максат итеп куелган. Тел өйрәнүчеләр, «Татар халкының тарихы», «Татар халкының күренекле шәхесләре», «Чит илләрдәге татарлар», «Татарстанның халыкара мөнәсәбәтләре», «Мәдәният һәм сәнгать дөньясында» кебек бүлекләрне өйрәнгәндә, үзләре өчен күпкырлы мәгълүмат алалар, тыңланган һәм укылган текстларның эчтәлегенә карата үз фикерләрен телдән һәм язмача белдерергә, күмәк сөйләшүләрдә катнашырга өйрәнәләр. Санап чыккан материаллар белән үзлегеннән танышу һәм аларны, күп тапкырлар төрле биремнәрдә кабатлап, гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә, тел өйрәнүченең сөйләм осталыгы көннән-көн үсеш ала, ул үзен тормыш шартларында актив аралашуга әзерли. Моннан тыш, онлайн-мәктәптә әйтелеш һәм язу бүлекләре; грамматик лаборатория; онлайн-сүзлек; 9 дәрәҗә өчен тикшерү тестлары; җанлы аралашу дәресләре өчен материаллар урын алган. Әйтелеш һәм язу кагыйдәләре бүлекләре, грамматик лаборатория тел өйрәнүчеләрнең лингвистик компетенциясен үстерүгә, татар телен тулы бер система буларак күзаллауга, кирәкле мәгълүматны тиз генә эзләп табу һәм искә төшерүгә, куелган коммуникатив бурычны хәл итүгә хезмәт итә. Белешмә материалларда татар теленең лексикасы, сүз төзелеше, сүзләрнең грамматик төркемнәре, сүзтезмәләр һәм аларның типлары, гади һәм кушма җөмләләрнең структурасы, орфоэпия, графика, орфография һәм пунктуация турында күпкырлы мәгълүмат бирелгән һәм уңышлы мисаллар белән аңлатылган. [5: 279].

Татар теле белән кызыксынучы, онлайн-мәктәптә теркәлгәннән соң, башта үзенең белем дәрәҗәсен ачыклый һәм билгеләнгән дәрәҗәдән татар телен өйрәнергә керешә. Онлайн-мәктәпнең интерфейсы 3 телдә бирелгән: татарча, русча, инглизчә. Димәк, тел өйрәнүче үзенә уңайлысын сайлый ала. Теркәлү яки эшләү барышында сораулар туса, интерфейстагы *Безгә мөрәҗәгать итегез* төймәсенә басып, үз соравын юллый, һәм онлайн-мәктәпнең махсус хезмәткәре аңа булышлык итә.

Һәр бүлек 4 дәрестән тора: тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу дәресләре. Аларда тел өйрүнүчеләр әңгәмәдәшләрен тыңларга, төрле сорауларга җавап бирергә, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлеген чагыштырырга, аларга карата үз фикерләрен телдән яки язмача белдерергә күнегәләр. Моның өчен һәр дәрес билгеле бер этапларга бүленгән: видеоязманы карау һәм сорауларга җавап бирү; яңа сүзләрне тыңлау һәм биремнәр аша үзләштерү; тел материалы белән танышу; сөйләм практикасы, язу. Һәр дәрес ахырында йомгаклау биреме тәкъдим ителә. Аны эшләгәндә, укучы шушы дәрестә үтелгән материалны искә төшереп кабатларга, сөйләмдә

ныгытырга һәм системалаштырырга тиеш була. Йомгаклау биременең әһәмияте шунда: алар әлеге дәрестә башкарылган эшләрнең кирәкле һәм кыйммәтле булуын күрсәтә.

Тел өйрәнүчеләр, беренче дәресләрдән үк, татар сөйләмендә актив кулланыла торган җөмлә калыпларын, тотрыклы гыйбарәләрне, клишеларны (исәнләшү, кем һәм кайдан булуы, кайда яшәве һәм эшләве турында әйтү, вакыт һәм һава торышы турында сорау, җавап кайтару, хәл белешү, рөхсәт сорау, үтенеч белдерү, телефон номерын әйтү, рәхмәт әйтү, саубуллашу һ.б.) гамәли үзләштереп, үзләре белән таныштыру һәм башкалар белән танышу, ягъни башлангыч дәрәҗәдә сөйләм оештыру күнекмәләренә ия булалар. Нәтиҗәдә, аларда татар телен өйрәнүгә уңай мотивация барлыкка килә. Һәр дәрестә уртача 20-25 күнегү бирелгән. Алар арасында иң еш очрый торганнары: «Видеоязманы карагыз һәм сорауларга җавап бирегез»; «Аудиоязманы тыңлагыз һәм дөрес җавапны сайлагыз»; «Сүзләрне тиешле тәртиптә куеп, җөмләләр төзегез»; «Аудиотекстны тыңлагыз. Җөмләләрне тиешле тәртиптә урнаштырыгыз»; «Текстны укыгыз. Хәзерге заман хикәя фигыльләрне билгеләгез»; «Сул баганадагы сүзләрне уң баганадагы сүзләргә туры китереп урнаштырыгыз»; «Сүзләрне рәсемнәргә туры китереп урнаштырыгыз» һ.б. Билгеле бер тема буенча өйрәнелә торган тел һәм сөйләм берәмлекләре, төрле күнегүләр эшләү барышында күп тапкырлар кабатланып, аңлы рәвештә гамәли үзләштерелә. Болай эшләү тел өйрәнүчеләрнең, тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу күнекмәләренә ия булып, җанлы аралаша башлауларына мөмкинлекләр тудыра. Шунысы мөһим: дәресләрдәге күпсанлы диалоглар, сөйләм күнегүләре, халык авыз иҗаты үрнәкләре, татар җырлары, танылган татар шагыйрьләренең шигырьләреннән алынган өзекләр, татар театры артистлары катнашында төшерелгән видеоязмалар, телевизион тапшырулардан алынган хәбәрләр «тел мохите» булдырырга ярдәм итә һәм укучыларда дәрестән дәрескә тотрыклы кызыксыну уята.

Төрле этаптагы күнегүләр системасы бәйләнешле сөйләм үстерү максатыннан бирелгән. Татар телен өйрәнүче ишетеп, укып, күреп кабул иткән мәгълүмат ярдәмендә аерым җөмләләр, диалогик һәм монологик хәбәрләмәләр төзергә, куелган сорауларга тиешле җавап репликаларын кулланырга, сөйләмне лексик-грамматик яктан дөрес формалаштырырга, электрон хатлар язарга күнегә. Тел өйрәнүче бүлектәге барлык күнегүләрне эшләп чыкканнан соң гына алдагысына күчә ала. Һәр бүлек ахырында аның эчтәлегенә бәйле мәгълүмат, гомумиләштерелеп, күзәтү форматында бирелгән. Биредә бүлекнең максатлары, һәр дәреснең исеме күрсәтелгән, актив сүзләрнең әйтелеше, транскрипциясе, язылышы, тәрҗемәсе урын алган. Барысы да уңайлы, җайлы һәм уйлап эшләнгән, шуңа күрә дә, компьютерның бер төймәсенә басып, кирәкле сүзне эзләп табарга һәм искә төшерергә мөмкин.

Телне өйрәнү барышының иң әһәмиятле этапларыннан берсе – үзләштергән белемнәрне һәм коммуникатив күнекмәләрне тикшерү һәм объектив бәя бирү. Шул максаттан чыгып, онлайн–мәктәптә һәр дәрәҗә ахырында тикшерү тесты тәкъдим ителә. Тестлар – йомгаклау тикшерү эшләрен оештыруда кулланыла торган иң эффектив дидактик бәяләү берәмлекләренең берсе. Моның белән беррәттән, алар тел өйрәнү процессын статистик яктан дөрес анализларга, җитешсезлекләрне күрергә һәм уку-укытуның сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә. Аларга түбәндәге сыйфатлар хас: барлык кешеләр өчен дә биремнәрнең бер типта булуы һәм аларның тиз кабул ителүе; нәтиҗәләрне бәяләүдәге объективлык; укытучының субьектив фикере исәпкә алынмавы. Дәрәҗә тестларын төзегәндә, түбәндәге критерийлар исәпкә алынган: *валидлык* (тестларның билгеле бер этаптагы тикшерүнең максатларына туры килүе); *корректлык* (тест биременең логик яктан эзлекле булуы һәм тестны эшләүгә комачауламавы). Онлайн-мәктәптәге дәрәҗә тесты 4 өлештән тора: грамматика, лексика, уку, тыңлап аңлау. Тел өйрәнүче грамматикадан 20 бирем, лексикадан 10 бирем, укылган текстларның эчтәлеге буенча 10 бирем һәм тыңланган текстларның эчтәлеге буенча 10 бирем эшләргә бурычлы. Димәк, тест тапшыручы һәр дәрәҗәдә барлыгы 50 бирем эшли.

Тыңлап аңлау өлешендә әңгәмәдәшләрнең көндәлек аралашу вакытында куллана торган гыйбарәләре, прагматик (белдерү) һәм мәгълүмати аудиотекстлар файдаланыла. Уку күнекмәләрен тикшергәндә, прагматик, фәнни-популяр, публицистик һәм әдәби стильгә караган текстлар алына. Тикшерү тестларындагы биремнәр тел өйрәнүчеләрнең

коммуникатив күнекмәләрен объектив рәвештә бәяләргә, эшнең нәтиҗәлелеген күзалларга мөмкинлекләр бирә. Дәрәҗә тестлары түбәндәге методик функцияләрне үтиләр: *өйрәтү функциясе* (татар телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү); *диагностик функция* (тел өйрәнүчеләрнең әзерлек дәрәҗәсендәге кимчелекләрне ачыклау); *тәрбияви функция* (тел өйрәнүчеләрнең үзтикшерү һәм үзбәяләү күнекмәләрен активлаштыру, белем алуга өстәмә этәргеч булдыру); *гомумиләштерү функциясе* [6: 26]. Әлеге функцияләр фәннилек, системалылык, объективлык кебек дидактик принциплардан чыгып билгеләнә. Тест тапшыручы һәр биремдә тәкъдим ителгән 4 җавапның берсен сайлап алырга тиеш. Биремнәрне уңышлы башкарып чыгу тел өйрәнүчеләрнең татар телен үзләштерү дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итә. Алар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш: тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлау; тыңланган тексттан кирәкле мәгълүматны табу; укылган текстның төп эчтәлеген аңлау; укылган тексттан кирәкле мәгълүматны табу; лексик-грамматик һәм орфографик күнекмәләргә ия булу. Биремнәрнең 70 % ын дөрес башкарган кеше дәрәҗә сертификатын алырга хокуклы. Моның өчен ул, *Минем прогресс* төймәсенә басып, кирәкле дәрәҗә сертификатын ача һәм әлеге документны бастырып ала. Интернет аша тел өйрәнүчегә мондый мөмкинлек тә бирелгән, ягъни укыту системасында барысы да каралган.

«АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбенең контентын булдыруда EF компаниясе хезмәткәрләре белән бергә республиканың бик күп белгечләре катнашты. Алар арасында Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты укытучылары, шулай ук мәктәп мөгаллимнәре, Татарстан китап нәшрияты редакторлары һәм корректорлары, Татарстан фәннәр академиясе хезмәткәрләре, медиаредакторлар, техник редакторлар бар. Шушы бердәм команда кыска гына вакыт эчендә тапшырылган эшне уңышлы башкарып чыкты. Нәтиҗәдә, онлайн-мәктәп үзенең эчтәлеге, видеоязмалары, кызыклы биремнәре, бизәлеше белән Россиядә генә түгел, хәтта чит илләрдә яшәүчеләрнең дә игътибарын үзенә җәлеп итте. Бигрәк тә, Казахстан, Төркия, Кытай, Австралия вәкилләре онлайн-мәктәптә татар телен бик теләп өйрәнәләр. Аңлашыла ки, бу илләрдә татар диаспоралары бик көчле, шуңа күрә андагы татарлар, туган телне буыннан-буынга тапшыру, аны саклап калу өчен, бөтен мөмкинлекләрдән файдаланалар һәм, Татарстан җитәкчелегенә рәхмәтләрен әйтеп, хатлар юллыйлар. Тел өйрәнүчеләр арасында Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүчеләрнең дә саны шактый зур.

Бүгенге көндә исә КФУ ның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе үзеге эшләп килә. Югары квалификацияле һәм махсус тренинг үткән филологлар көн саен онлайн-режимда тел өйрәнүчеләр белән җанлы аралашу дәресләре алып баралар. Мондый дәрес 45 минут дәвам итә, һәм анда 6 кеше катнаша ала. Дәресләр һәр дәрәҗәнең аерым бер темасы буенча алдан әзерләнгән слайдлар һәм тел материалы нигезендә үткәрелә. Һәр дәрәҗәнең өйрәнелә торган бүлегенә бәйле урнаштырылган рәсемнәр, күнегүләр, диалогик сөйләм үрнәкләре, аралашу ситуацияләре ярдәмендә укытучы, һәр катнашучының сөйләм күнекмәләрен үстерү максатын һәм аларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, компьютер аша дәрес алып бара. Укытучы дәресен кереш әңгәмәдән башлый, чөнки һәр дәрескә яңа укучылар керергә мөмкин. Барлык кулланыла торган алымнар, бер яктан, тел өйрәнүчеләрнең коммуникатив күнекмәләрен камилләштерүгә китерсә, икенче яктан, башкалар белән үзара аралашу аларда зур кызыксыну һәм омтылыш уята. Димәк, җанлы аралашу дәресләре тел өйрәнүчеләрнең сөйләмен үстерү һәм аларның активлыгын таләп итә торган күмәк эш төрләрен куллануга, дәресләрдә тел мохите булдыру һәм укытучының аралашу процессы белән методик яктан идарә итүенә китерә. Бу очракта укытучы татар телен үзләштерүчеләрнең коммуникатив эшчәнлегенә актив җитәкчелек итә белергә тиеш.

Укытучыдан шулай ук дәрестә үзара хезмәттәшлекне оештыру һәм аны гамәлгә куюга юнәлтелгән коммуникатив күнекмәләр формалаштыруга да тиешле игътибар бирү сорала. Төркемдә аралашу барышында тел өйрәнүчеләр бер-берсенең фикерен тыңларга һәм исәпкә алырга, әңгәмә корырга, ярдәмләшергә өйрәнәләр. Алар, укытучының күрсәтүе буенча, билгеле бер эзлеклелектә төрле биремнәр эшлиләр, үзара сөйләшүләр үткәрәләр. Җанлы әңгәмә дәрес темасы кысаларыннан киңәеп тә китә ала, чөнки тел өйрәнүчеләрдә тормыш вакыйгалары турында да фикер алышу, аларга укытучының шәхси

мөнәсәбәтен белү теләге барлыкка килергә мөмкин. Дәресләр аларны бер-берсенә якынайта, үзара дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыруга булышлык итә. Иң кызыгы – төрле яшьләрдәге кешеләр, үз тырышлыклары белән, гамәли эшләр аша сөйләмен үстерерү, нәтиҗәләр чыгару һәм җанлы аралашу вакытында аларның дөреслеген тикшерү мөмкинлегенә ия булу сәбәпле, әлеге дәресләрдә дәртләнеп һәм кызыксынып катнашалар. Нәкъ менә сөйләшү дәресләрендә алар теманы ничек өйрәнүләрен, нәрсәләрне яхшы үзләштерүләрен, ә кайсыларын белеп бетермәүләрен ачык күрә алалар. Шулай эшләгәндә генә, тотрыклы күнекмәләргә, ягъни, белгәннәргә таянып, коммуникатив мәсьәләне чишә алу осталыгына ирешеп була. Дәрес ахырында исә укытучы барлык катнашучыларга уңышлар теләп саубуллаша. Аннары укытучы, системага кереп, һәр укучының эшчәнлегенә язмача бәя бирә, кирәк урында мактап яки искәрмә ясап, хаталарын күрсәтә, комментарийлар яза һәм баллар куя. Соңыннан тел өйрәнүчеләр әлеге мәгълүмат белән таныша алалар.

«АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе үзәге укытучылары үзләренең эш тәҗрибәләре белән бик теләп уртаклашалар, республикада һәм башка төбәкләрдә үткәрелә торган семинарларда һәм конференцияләрдә дистанцион укыту алымнары турында чыгыш ясыйлар. Казан университеты кунакларында да шундый заманча дистанцион мәктәп зур кызыксыну уята.

Башка Интернет-ресурсларга килгәндә, татар теле белән кызыксынучыларга тагын *tatarile.org* порталында башлап өйрәнүчеләр өчен тәкъдим ителгән (А1 дәрәҗәсе) «Татар теле» курсы турында мәгълүмат бирү файдалы булыр [7]. Алда әйтелгән онлайн-мәктәптән аермалы буларак, әлеге курсның төп максаты – татар телен өйрәнүчеләргә башлангыч фонетик, лексик һәм грамматик белем бирү; аерым сүзләрне, җөмләләрне һәм кечкенә текстларны тыңлап аңлау, уку һәм язу күнекмәләрен үстерү. «Гаилә», «Тышкы кыяфәт», «Йорт. Фатир», «Һөнәрләр», «Спорт һәм ял», «Татарстан Республикасы», «Россия Федерациясе» һ.б. темалар телдән һәм язма сөйләм үстерү өчен тәкъдим ителгән. Башлангыч грамматик материал сөйләмдә еш кулланыла торган исемнәр, саннар, сыйфатлар, алмашлыклар, фигыльләр һәм аларның төп категорияләрен үз эченә ала. Һәр дәрес рәсемнәр, аудиоматериаллар белән тәэмин ителгән. Әлеге курсның да алга таба дәвамы булса, нәтиҗәсе тагын да зуррак булыр иде. Методик хезмәтләрдә билгеләп үтелгәнчә, шундый информацион-коммуникатив укыту чаралары булдыруның актуальлеге телгә өйрәтү процессына төрле шәхесләрнең чын аралашу үрнәкләрен кертүдән гыйбарәт [8: 412].

Әйтелгәннәрдән чыгып, традицион укыту методлары белән чагыштырганда, Интернет-технологияләр аша тел өйрәнүнең берничә өстенлеген билгеләп үтәргә мөмкин: телне теләсә кайсы урында һәм вакытта өйрәнү; җанлы аралашу дәресләрендә алган белемнәрне гамәлдә кулланып карау һәм үзбәя бирү; телне өйрәнү барышында барлыкка килә торган уңайсызлыклар, психологик киртәләр һәм киеренкелек булмау; дөньяның төрле почмакларында яшәүче кешеләрне берләштерү; яңа кешеләр белән танышу нәтиҗәсендә эмоциональ комфорт тойгысы булдыру [9: 17]. Тәҗрибә күрсәткәнчә, яңа педагогик технологияләргә нигезләнеп булдырылган укыту чаралары теләсә кайсы телне дөньяда таныту һәм таратуга хезмәт итә. Шуны да әйтеп үтәсе килә: заманча технологияләр традицион укыту системасын алыштыру өчен түгел, ә аны тагын да баету, тел белән кызыксынучыларга һәм яңалыкка омтылучыларга компьютер аша өйрәнү мөмкинлекләре тудыру өчен эшләнә. Онлайн-мәктәптә уку дәверендә тел өйрәнүче, коммуникатив бурычны хәл итүдә, төрле ысулларны мөстәкыйль файдаланып, максатына ирешергә күнегә.

Татар теленнән дистанцион чараларның булуы белән без, һичшиксез, горурланабыз. Туган тел белән кызыксынучыларга, аны өйрәнергә теләүче төрле милләт вәкилләренә «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбен тәкъдим итәбез. Яңа технологияләр һәр укытучы алдына хәл ителергә тиешле мөһим мәсьәләләрне көн тәртибенә куя тора. Шуңа күрә дә республикада һәм Россиянең башка төбәкләрендә хезмәт куючы татар теле укытучыларының да онлайн-мәктәптән, андагы эш алымнарыннан һәм телләргә өйрәтү өлкәсендәге яңалыклардан хәбәрдар булулары, туган телебезгә өйрәтүдә алардан максатчан, урынлы һәм нәтиҗәле файдалана белүләре, заман белән бергә атлап барулары, читтә калмаулары әһәмияткә ия. Бары тик яңалыкка омтылу гына үсешкә китерә ала.

Гомумән алганда, татар теленә өйрәтүдә дистанцион укыту чараларын эзлекле рәвештә гамәлгә кертү, мультимедиа технологияләрен-

нән киң файдалану юнәлешендә эшне тагын да активлаштыру сорала. Алар татар телен укыту гына түгел, ә саклау һәм үстерү чаралары да булып торалар, чөнки дөньяның төрле илләрендә яшәүче кешеләргә татар теле белән танышырга, аны үзләштерергә һәм аралашуда кулланырга мөмкинлек бирәләр. Моннан тыш, тел өйрәнүчеләр коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белергә, адекват аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдаланырга, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булырга күнегәләр. Татар телен укытуны заманча оештыру, яңа дистанцион курслар булдыру һәм Интернет мөмкинлекләреннән күбрәк файдалану – һәрбер кешенең бурычы. Ирешелгән уңышлар алга таба да әлеге юнәлештә эзлекле эш алып бару өчен нигез һәм этәргеч булып торсын иде.

**Әдәбият**


1. *Донецкая О.И.* Интернет-технологии в обучении иностранным языкам. Казань: Каз. гос. ун-т, 2009. 79 с.
2. «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе // URL: http://anatele.ef.com
3. *Полат Е.С., Бухаркина М.Ю.* Современные педагогические и информационные технологии в системе образования: учеб. пособие для студ. высш. учеб. заведений. М.: Академия, 2007. 368 с.
4. *Соловова Е.Н.* Методика обучения иностранным языкам: Базовый курс лекций. 2-е изд. М.: Просвещение, 2003. 239 с.
5. *Замалетдинов Р.Р., Фатхуллова К.С., Юсупова А.Ш.* Из опыта использования мультимедийных технологий в обучении татарскому языку // Филология и культура. Philology and Culture. 2013. № 3 (33). С. 277-281
6. Тестирование в обучении русскому языку как иностранному: современное состояние и перспективы /По ред. Т.М.Балыхиной. М.: МГУП, 2003. 189 с.
7. «Татарский язык для всех» онлайн-курсы // URL: http: // tatarile.org
8. *Ладыженская Т.М.* Проблемы использования Интернет-технологий для формирования коммуникативной компетенции на уроках русского языка // Материалы второй Международной научно-практической конференции «Полатовские чтения 2009: Дистанционное обучение в предметных областях». Казань: ЮНИВЕРСУМ, 2011. 432 с.
9. *Кабанова Т.А., Новиков В.А.* Тестовые технологии в дистанционном обучении. М.: Изд. Дом «Обучение-Сервис», 2008. 320 с.


---

# ДИСТАНЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ В ОБУЧЕНИИ ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ


**Кадрия Сунгатовна Фатхуллова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д.18,
kadria.kgu@ mail.ru.



В статье предоставлена информация о содержании дистанционного обучения татарскому языку, рассмотрены цели и задачи курса, методические особенности преподавания татарского языка; описывается структура дистанционных курсов, приемы работы и типы упражнений, направленных на овладение татарским языком как средством межличностного и межкультурного общения. В современных условиях использование дистанционных средств обучения, когда существует возможность одновременного использования графики, текста, видео, анимации, звуковых эффектов, вызывает большой интерес. Программа дистанционных курсов предполагает не только самостоятельное усвоение лексики и грамматики, овладение навыками аудирования, чтения и письма, в ней также предусмотрено обучение устной и письменной речи, представляющее собой целостную методическую систему. Пользователи онлайн-школы, опираясь на полученные знания, участвуют в живых разговорных уроках, знакомятся с людьми, проживающими в разных уголках мира, учатся вести с ними беседу и обмениваться мнениями, в результате чего они овладевают коммуникативной компетенцией.



**Ключевые слова:** лингвометодика, татарский язык, средство общения, дистанционное обучение, онлайн-школа, коммуникативная компетенция, виды речевой деятельности, уровневый тест.